| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>10 июля 2015 года | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>№546 |

Зеленодольск муниципаль район Советының 2014 елның 05 ноябрендәге 460 номерлы Татарстан Республикасының "Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләренә белешмәләр бирү нигезләмәсен раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

2014 елның 22 декабрендәге 431 номерлы «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 23 мартындагы УП 308 номерлы «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» Указын исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль район Советының 2014 елның 05 ноябрендәге 460 номерлы Татарстан Республикасының "Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләренә белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарының 1 пунктындагы өченче абзацында (алга таба – Карар) “гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә, үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә, шулай ук хатынының

(иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган, һәм” сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләренә белешмәләр бирү турында карары белән расланган нигезләмәгә” түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданинга керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү бурычы йөкләнә (алга таба - гражданин).

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендәге хисап елының 31 декабренә муниципаль хезмәт вазыйфасын алыштырган, муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә һәм җирле үзидарә органы вазыйфаларының (муниципаль орган) тиешле исемлегенә кертелгән 2 нче кушымтаның 2 пунктында күрсәтелгән (алга таба-вазыйфалар исемлеге) муниципаль хезмәткәренә (алга таба - муниципаль хезмәткәр) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру бурычы йөкләнә.

2.2) 3 пунктта ",вазыйфалар исемлегендә каралган" сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3) 6 пунктның «в» пунктчасында:

2.3.1) «әгәр алыш-биреш суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш кылуга кадәрге өч ел эчендә гомуми кеременнән артып китсә» сүзләрен «әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч ел эчендә гомуми кеременнән артып китсә» сүзләренә алмаштырырга;

2.3.2) «алыш-биреш башкарылган» сүзләрен «бу алыш-бирешләр башкарылган» сүзләренә алмаштырырга;

2.4) 7 пунктта:

2.4.1) “вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы " сүзләрен «муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче» сүзләренә алмаштырырга;

2.4.2) "2, 3 һәм 5 пунктлар нигезендә" сүзләрен "2, 3 һәм 5 пунктның беренче абзацы нигезендә" сүзләре белән алыштырырга;

2.5) 8 нче пунктта "җирле үзидарә органы (муниципаль орган) башлыгы исеменә" сүзләрен төшереп калдырырга;

2.6) 13 пунктта:

2.6.1) "алыш-биреш башкарылган" сүзләрен “алыш-бирешләр ясалган (алыш-биреш ясалган)” сүзләренә алмаштырырга;

2.6.2) «әгәр алыш-биреш суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш кылуга кадәрге өч ел эчендә гомуми керемennән артып китсә» сүзләрен «әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге өч ел эчендә гомуми керемennән артып китсә» сүзләренә алмаштырырга;

2.7) 15 пунктның икенче абзацында «вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасына» сүзләрен «алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына» сүзләренә алмаштырырга.

3. 2 нче кушымта Карарына “гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган, һәм” сүзләрен төшереп калдырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**